УДК 930.1

Г. ГОБӘЙДУЛЛИН ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ «ХАЛЫК», «МИЛЛӘТ» ТӨШЕНЧӘЛӘРЕ

Э.К. Сәлахова

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты
Казан, Россия Федерациясе
ilsalah@mail.ru

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы – татар халкы тарихында үткәннәргә борылып карау, тарихи һәм мәдәни мәсьәләләр хакында фикерләү, киләчәккә, үсешкә бурычлар билгеләү вакыты. Бу чорда татар галимнәре һәм публицистлары хезмәтләрендә «миллилек»нең асылын ачыклау, «халык», «милләт» төшенчәләре хакында фикерләү алгы планга чыга, «Без кем?» дигән сорауга җавап эзләү күзәтелә.

Тәкъдим ителгән мәкаләдә автор күренекле татар галиме, тарихчы һәм педагог Газиз Гобәйдуллинның «Милләтне ничек тәгъриф кылырга?» (1913) «Төрекме, татармы?» (1918), «К вопросу о происхождении татар» (1928) дигән хезмәтләренә таянып, аның татар халкына халык исеме буларак бирелгән атамасы, татарның милләт булып формалашуы хакындагы фикерләренә анализ ясый, галимнең татар халкының асылы проблемасы хакындагы фикер үсешен күрсәтергә омтыла. Г. Гобәйдуллиның бу проблема хакындагы фикере аның замандашлары фикере белән чагыштыруда бирелә.

Соңгы вакытта татар халкының асылы, эчтәлеге хакында кызыксыну арта. Проблема бүген дә актуаль, шуңа да XX гасыр башы галимнәренең бу хактагы фикерләре аеруча мөһим яңгыраш ала. Әлеге тикшеренүнең фәнни яңалыгы шул чор татар җәмгыятендәге халык исеме буларак кулланылган атама һәм милләт булып оешу хакындагы фикерләрне татарның беренче профессиональ тарихчысы Г. Гобәйдуллин хезмәтләре аша күрсәтүдән гыйбарәт.

Ачкыч сүзләр: милләт, милли тәңгәллек, халык, тарихчы Г. Гобәйдуллин, миллилек, тарих, мәдәният.

Тарих, тарихи вакыйгалар – алар тормышның үзе, кешелек тормышының чагылышы. Шуңа да тарихта булган ниндидер проблема гасырлар үтеп тә актуальлеген югалтмый, яңадан калкып чыгып, фикер алышуга китерә икән, моңа бары бер табигый күренеш итеп карау кирәклеге аңлашыла. XX йөз башында татар җәмгыятендә күп төрле фикерләр уяткан, шактый бәхәсләр китереп чыгарган мәсьәләнең берсе – ул халыкның үткәне, аерым алганда, аның килеп чыгышы, исеме һәм

аның милләт буларак формалашу процессы. Бу сораулар бар халыкка да кагылган, гади халык аны үз яшәеше белән күрсәтсә, татар зыялылары, язучылар, галимнәр, проблеманы фәнни нигездә тикшереп, анализлап, үз фикер сөрешләрен матбугат битләрендә яктыртканнар, хезмәтләрендә, әсәрләрендә чагылдырганнар. XX йөз башы матбугатында «Без кем?» дигән сорау иң популяр сорауларның берсе булган дәвер бар. Бу чорда татарларның төрле этнографик төркемнәре турында да кызыксыну арта. Фәннилек дәрәҗәсе белән аерылып торган «Шура» журналына мондый сорауларга җавап табу, аңлау өмете белән гади кешеләр дә хатлар яудыралар. «Шура» белән мөхәррирлек иткән Ризаэтдин Фәхретдин бу тарихи проблемалар буенча һәр санда диярлек үз фикерләрен биреп бара, мәкаләләр урнаштыра. Журнал битләрендәге язмаларда татар халкының формалашу этаплары, исеме, аның төрле этнографик төркемнәре хакындагы мәгълүматларның халык өчен ни дәрәҗәдә кызыклы һәм әһәмиятле булганлыклары күренә. Озак вакытлардан килгән бу кызыксыну, фикер төрлелегенә җавап биреп, Ш.Мәрҗани проблеманы фәнни калыпка керткән булса да, бу соңгы сүз, соңгы нокта була алмаган, аннан соң яшәгән һәм иҗат иткән галимнәр, язучылар үз хезмәтләрендә «милләт», «халык» атамалары хакында фикерләүне, язуны дәвам иткәннәр (Мәрҗани 1989: 1–36). XX йөз башында бу фикер алышулар ике яссылыкта бара: берсе – И. Гаспралыдан килгән «төркичелек» булса, икенчесе – «татарлык»ны алга сөргән юнәлешләр.

Газиз Гобәйдуллин да халык исеме хакында үз фикерләрен белдергән язмалар белән матбугатта чыгыш ясый. Татарның тарихи белем алган беренче профессиональ тарихчысының фикер сөреше аеруча кызыклы, аның язмалары фикер тирәнлеге белән аерылып тора (Насретдинова 1997: 5–26). Г.Гобәйдуллинның «Төрекме, татармы?» дип исемләгән мәкаләсе 1918 елда «Корылтай» газетасында дөнья күрә (Газиз 1918а), шул ук елны аны аерым китапчык итеп тә чыгаралар (Газиз 1918б). Бу мәкаләсендә автор Идел буе татарлары өчен нинди атама – «төрек»ме, яисә «татар» туры киләме, ни өчен туры килү-килмәвен тарихи яссылыкта күрсәтә. Бу хакта бик озак бәхәс барса да, күп фикер әйтелсә дә, әлегә кадәр атаманы ошату-ошатмау турында гына сүз йөртүгә кайтып калына дигән фикердән чыгып, галим бу мәсьәләгә инде фәнни күзлектән карап сүз әйтергә вакыт җиткәнлеген күрсәтә. Үзе исә, мәкаләнең беренче юлларында ук, сорауны болай кую дөрес тә түгел дип искәртә, аның карашынча, бу «Без төрекме, әллә монголмы?» дип сорауга тиң була. Аның өчен «татар» белән «монгол» бер үк мәгънәдәге атамалар. Г. Гобәйдуллин мәкаләсендә үзенең әлеге күзаллавын дәлилләү өчен тарихтан, тарихи чыганаклардан мөмкин кадәр

күбрәк мисаллар китерергә омтыла, хәтта ки бу фикеренә башкаларны да кирәгеннән артыграк та инандырырга тырыша, дигән тәэсир кала.

Бу очракта, ялгыш фикерләргә урын калмасын өчен, XX йөз башында «төрек» атамасының төрки халыкларга карата кулланылган атама булуын ачыклап куярга кирәк, биредә хәзерге төрек халкы хакында сүз бармый. Мәгълүм булганча, татарлар үзләренә карата кулланылган бу атаманы бары тик читләр тарафыннан тагылган итеп, аның бары тик тискәре эчтәлеген генә күрәләр. Шуңа күрә дә халык үзен, дини яктан ассызыклап, «мөселман» дип атауны тиешлерәк дип санаган. Бу аңлашыла да, чөнки гасырлар дәвамында барган диннән яздыру сәясәтеннән иза чиккән халыкның бу якка басым ясавы, бу атаманы куллануы табигый хәл.

Идел буе татарлары өчен «мөселман» атамасын куллану халыкның тулы бер өлешен аңлатмый. Г. Гобәйдуллин фикеренчә, болай атаган очракта халыкның бер өлеше булган, әмма дин ягыннан аерылып торган «керәшен» татарлары төшеп кала, һәм бу дөрес булмас иде. Идел буенда яшәүче халык, хәзерге татарлар, галим фикеренчә, «Урал-Алтай кавеменнән [нәселеннән] булып, бу кардәш кавемнәрнең «төрек» җенесенә мәнсүб [караган] булганнарыннандыр. Аның хәзерге теле, тарихы, әдәбияты, хәтта кабер ташларына кадәр моңа шаһитләрдер» (Газиз 1918б: 2). Идел буе төркиләре тормышына «татар» атамасы яу белән генә килгән: «Шулай итеп, монгол-татарлар хәзерге җәнүби [көньяк] вә шәркый [көнчыгыш] Русия төрекләренә һөҗүм кылганнар, аларның үз сәяси хәятләрен җимергәннәр. Аның урынына монгол хакимияте корганнар иде», – дип яза (Газиз 1918б: 2). «Татар» исеме яулаучылар белән тиңләштерелеп, үзенә тискәре төсмер алу сәбәпле, галим «мөселманнар һаман да шул татарлыктан качалар, вә үзләренең телләрен «төрки тел» дип атыйлар, шигырьләрен «төрки» дип исемлиләр, әдәбиятларын «төрки» телдәге китаплар диләр иде», ди, бу атаманың негатив төсмергә ия булганы өчен генә түгел, ә халыкның асыл тарихын, асыл эчтәлеген аңлатмаганга, халык атамасы буларак үзен акламаганын аңлатырга тырыша. «Гомумтөркичелек идеясен тәгъкыйб кылу да [күзәтү] безне, Волга мөселманнарын, төрек дип әйтергә урын калдырадыр» (Газиз 1918б: 7). Татар этнонимына мөнәсәбәт озак вакытлар зыялылар тарафыннан да бик уңай булмый, исем итеп «төрки» сүзен куллану озак дәвам итә. Мисал өчен, Г. Баттал татар тарихына багышланган хезмәтенең исемен дә «Казан төркиләре» дип куя (Баттал 1996: 189).

1918 елдагы мәкаләсенә караганда, Г. Гобәйдуллин үзен «төркичелек» идеясе тарафдары итеп күрсәтә, тарих, халыкның исеме турындагы фикерләвенә нәтиҗә ясап, беренчедән, «татар» исеме Урта Русия төрекләренә рус һәм европалылар тарафыннан бирелгән,

икенчедән, «татар исеме безнең илгә килгән монголларның падишаһлары, нәселләре безгә падишаһ булып утыргач, безгә бирелгән исемдер», өченчедән, «безнең атымыз «Волга төрекләре» булырга тиештер. Халкымыз арасында татар сүзенә илтифат вә хөрмәт юк; аны яратмыйдыр», – дип яза (Газиз 1918б: 11). Галимнең 1928 елда язылган «К вопросу о происхождении татар» дигән хезмәте югарыда куелган проблемага карата авторның карашы үзгәргәнен күрсәтә (Газиз 1928: 131–141). Гәрчә ул, нигездә, 1918 елгы мәкаләсен язгандагы чыганакларга таянса да, ясаган нәтиҗәләре белән аерылып тора. Беренчедән, һәр тарихчы, галимнең фикере аның тәжрибәсе белән үзгәрергә мөмкин – бу табигый хәл, әмма шулай да бу очракта фәнгә сәясәтнең тәэсире сизелә. Милләт проблемасы хакында бәхәс аренасы булган шул чорның фикер ияләре үз карашларын белдергән «Шура» һәм «Аң»ны ул татарның фәнни яки ярымфәнни буржуаз журналлары дип атый. Кайчандыр татар зыялылары «төркичелек»не якларга мәҗбүр булса, Октябрь инкыйлабыннан соң бу проблеманы чишүгә без тулысынча объектив һәм фәнни карый алабыз, дип яза. Рус телендә язылган мәкаләсендә бу хакта ул: «Мы принимаем название «татар» для народности тюркского происхождения, живущей в Среднем Поволжье, как название исторически вполне законное и научное, определяющее данную народность и отделяющее ее от других, как название определенной этнической группы», – ди (Газиз 1928: 131). Бу очракта инде Г. Гобәйдуллин «татар» атамасын «монгол» сүзе белән тиңдәш итеп күрсәтми, аның өчен «татар» дигән исем «төрки» дигән мәгънәдә йөри, ул «татар» атлы кабиләнең монголлар эпохасына кадәр үк яшәгәнлеген һәм аларның мөһим бер халык булуы хакында сүз йөртә. «Татар» атамасын ике яссылыкта карарга була, бу ике яссылык бер-берсенә тулысынча капма-каршы мәгънәгә дә ия булырга мөмкин. «Татар» атамасына сәяси яктан, ягъни татар дәүләте астында берләшкән халыклар, кабиләләр җыелмасы буларак карамыйча, этнографик я антропологик мәгънәдә караган вакытта, татарлар монголлар да, шул ук вакытта алар төрки кабилә вәкилләре дә. Г. Гобәйдуллин үзенең элегрәк дөнья күргән мәкаләләрендә татарларны монголлар итеп каравын таный, хәтта казан татарларын «татар» дип түгел, ә «төркиләр» дип атауны яклавын да күрсәтә. Моны шулай эшләвен заман ихтыяҗлары белән аклый, шул ук вакытта, аның фикере буенча, татар-монголлар яулап алучы буларак, Көнчыгыш Европа халыкларына, шул исәптән, төрки халыкларга да, яу белән килгән икән, яулап алучылар исеме белән халыкны атау дөрес булмас дигән уй белән, Идел буе мөселманнарын «татар» исеме белән атауны якламый. 1928 елда тарихчының бу мәсьәләгә фикере үзгәреш кичерә, шулай булган очракта да, ул мәсьәләгә тарихи яктан якын килеп, тирәнрәк карау кирәклегенә басым

ясый. Аның фикеренчә, халык исеме буларак этнографик эчтәлек түгел, ә сәяси эчтәлектәге атама бирелүенә тарихтан күп кенә мисаллар китерергә була. Вакыт узу белән, сәяси атаманың бердәм дәүләт составына кергән башка халыкларга нисбәтле кулланылуы да билгеле. Г. Гобәйдуллин тарихи процесс дәвамында бер үк сүзнең төрле эчтәлек алуы, аның асылы үзгәрүен дә танырга кирәк дип саный һәм ул бу тезисын тарихтан төрле мисаллар белән расларга тырыша. Татар халкының формалашуын ул бары Казан ханлыгы чоры белән генә бәйли, билгеле сәяси шартлар чорында галим өчен Алтын Урда чорын татар тарихының мөһим бер этабы итеп карау мөмкинлеге булмаган. Аның «татар» этнонимы хакындагы фикерләре 10 ел дәвамында шактый үзгәреш кичерә, үзгәрешкә галим фикере генә нигез булмыйча, бу мәсьәләдә җәмгыятьтәге сәяси вазгыять тә зур роль уйный. Аның соңгы мәкаләсе «Татарны өйрәнү җәмгыяте» кысаларында эшләнгән һәм шул оешманың «Вестник научного общества татароведения» журналында басылган (Губайдуллин 1928: 131–141). Г. Гобәйдуллин 1923 елда оешкан әлеге оешманың әгъзасы булып торган, 1928 елга кадәр җитәкчелектә Галимҗан Ибраһимов торган. Җәмгыять рәисе урынбасары вазыйфасын үтәгән Г. Ибраһимовның фикерләре дә Г. Гобәйдуллин фикерләре белән аваздаш. Халык исеме буларак «татар» сүзе кулланыла икән, без моның белән килешергә тиешбез, чөнки мондый күренеш татарлардан кала башка халыкларда да күзәтелә: «әмма аңа карап, һичбер вакыт бездән «татар» дигән сүз алынмас. Ул яңлыш булыр, бөтен дөнья аның яңлышлыгын белер, аның зур афәте дә булыр, шул хәлдә дә ул алыштырыла алмас. Чөнки ул мәхаль [урынлы] бер эш. Андый бер мәртәбә бирелгән исемнәрне, яңлыш булса да, әүвәлгечә дәвам иткәнлегенә адәмнәрдә, фәнни истилахларда, милләтләрнең, мәмләкәтләрнең – хәтта Америка шикелле бөтен бер кыйтгаларның – исемнәрендә дөнья тулы мисал» (Ибраһимов 2007: 10).

Г. Гобәйдуллинның татар халкының этнос буларак формалашуы гына түгел, ә аның милләт булып җитешүе хакындагы фикерләре дә игътибарга лаек, чөнки халыкның милләт югарылыгына күтәрелүе – ул аеруча мөһим күрсәткеч. Шуңа күрә дә, Г. Гобәйдуллин татарны халык буларак өйрәнүдән алдарак та, мөгаен мөһимлек ноктасыннан карап, милләт буларак анализлауга багышланган мәкаләләре белән чыгыш ясый. Авторның бу мәкаләләре «Аң» журналында 1913 елда ук дөнья күрәләр. «Аң» журналы бу мәсьәләгә ачыклык кертү һәм татар зыялыларның фикерләрен җыеп, укучыларга тәкъдим итү максаты белән, «милләт» төшенчәсен билгеләү буенча 15 сораудан торган сораштыру тәкъдим итә. Шулар арасында: «милләт» нинди төшенчә, милләтнең нигезен нәрсә тәшкил итә; яисә, милләт дин, тел, Ватан белән бәйлеме; «милләт» һәм «милли рух»ның эчтәлеге нинди һ.б.

«Милләт»не күзаллау, бу төшенчәгә салынган эчтәлек белән кайбер фикерләр аерылып та торалар, һәр фикер иясе үз күзаллавын үз дәлилләре белән раслый. «Аң» журналында бу дискуссиягә фикерләрен шул заманның билгеле шәхесләре Г. Гобәйдуллин, Г. Шәрәф, З. Кадыйри һ.б. белдерәләр. XX йөз башында барган дискуссияләрдә инде әйтеләсе сүзләр әйтелгән, бу хактагы мәсьәлә хәл ителгән кебек тоелса да, соңгы елларда, инде йөз ел вакыт узып киткәннән соң, бу сорауларны халык үзе кабат күтәреп, яңадан, заман күзлегеннән карап бәхәсләшеп алды. 2021 елгы халык санын алу вакыты «милләт» мәсьәләсенең һәрвакыт актуаль калачагын, халыкның, ничә йөз еллар узуга да карамастан, әлеге өлкә белән кабат-кабат кызыксыначагын күрсәтте. Тарихтан мәгълүм булганча, күп кенә нәрсәләрнең, вакыйгаларның күпмедер вакыттан соң кабатлану мөмкинлеге бар, онытылган проблемаларга яңадан карау, заманча күзлектән чыгып анализлау гына түгел, күп вакыт моннан берничә йөз ел элек үткәрелгән карашлар белән үзара параллельләр үткәрергә дә кирәк була.

Г. Гобәйдуллинның да «милләт» турында әйтелгән күп кенә фикерләре хәзерге вакытта актуаль яңгырый. Аның 1913 елда басылып чыккан «Милләтне ничек тәгъриф кылырга?» дигән язмасында хәзерге җәмгыять алдында торган күп кенә сорауларга да җавап табарга мөмкин. Хәзер милләтне ничек тәгъриф кылырга [аңлатырга]? Туган телен белмәгән, үз телендә сөйләшмәүче хәзерге заман татарлары милләт вәкилләреме, юкмы? Милләтнең нигез ташларының берсе – динме? Соңгы вакытта татар җәмгыяте каршына куелган төп проблемалардан берсе – тел югалу. Туган телендә аралашмаган, күп очракта хәтта исеме дә татар исеменнән ерак булган, әмма ләкин үз тарихын, үз халкын хөрмәт иткән, җәмгыятькә хезмәт иткән кешене татар милләте вәкиле итеп кабул итәбезме? Яисә милләт вәкиле булу өчен милләтнең туган телендә аралашу мәҗбүри шартмы? Бүгенге җәмәгатьчелек тә бу сорауга бертөрле генә итеп, кистереп җавап бирә алмый. Татарлар гасырлар дәвамында үзләрен мөселман исеме белән атаганнар икән, дин шулай ук милләтне билгеләүче фактор була аламы, бер дин тотучылар бер милләтне тәшкил итәләрме, яисә бер милләттә бер дин генә булу мәҗбүри шартмы?

Г. Гобәйдуллин фикерләве буенча, беренче чиратта милләтнең төп билгесе – аның «инсаннар җыены» булуы. Инсаннарны, ягъни кешеләрне берләштерә торган билгеләрне тану мөһим. Бу очракта ул мондый билгеләр турында фикерләрен әйтә. Мисал өчен, дин. «Шактый гына милләтләрнең бер динле, бер дингә ышанганлыкларын күрергә тугры килә, шуңар күрә дә милләтнең хассасы [үзенчәлеге] «дин» түгелме мәсьәләсе хәтергә килә» (Газиз 1913а: 137–138). Тарихтан мәгълүм булганча, бер үк милләт булып формалашкан халыклар ара-

сында да төрле дин тоту очракларына мисаллар бар. Мәсәлән, алманнар, аларның бер өлеше протестант булса, икенчеләре католик, әмма бу төрлелек аларга бердәм милләт буларак яшәүләренә комаучауламый, дип саный галим. Без моңа татарның үз тарихыннан да инана алабыз: мөселман татарлар белән христиан динен тотучы керәшен татарларының бер милләтне тәшкил итүе – моның ачык мисалы. Дин милләтне билгеләүче бердәнбер билге булмаса да, аның бердәм булуының уңай яклары барлыгын да билгеләп: «Ләкин башка милләтләр белән күрешкәндә «дин»нең әһәмияте юк дия алмыйбыз. Чөнки халкына, аның мәдәниятенең дәрәҗәсенә күрә дин шактый гына милләтләрнең куәтләнүенә, башка милләтләр белән көрәшүенә ярдәм итә. Вакыйган, без татар-төрек милләтләренең Волга буендагыларының милләтләрен саклауда исламның зур гына файдасы булганлыгын күрәмез», – дип яза Г.Гобәйдуллин (Газиз 1913б: 137).

Тел мәсьәләсе, тел бердәмлеге милләтнең нигезе, әлбәттә. Әмма ләкин Г. Гобәйдуллин фикеренчә, бары тик тел генә милләтне билгели алмый. Моны раслап, ул шактый дәлилле мисаллар китерә. Хәзерге вакытта да бу татар җәмгыятенең четерекле бер проблемасы, чөнки билгеле шартлар нәтиҗәсе буларак, татар теле татар җәмгытенең бар әгъзасы өчен дә аралашу теле түгел. Г. Гобәйдуллин дөньядагы иң бердәм милләт – яһүдләрне мисал итеп китерә, яһүдләр, төрле дәүләт составында яшәп, төрле телләрдә аралашырга мәҗбүр булсалар да, аларның бер милләт булуын беркем инкяр итә алмый. Бары тел генә милләтне билгеләүче булмавына мисаллар җитәрлек. Инглиз телендә сөйләшүче халыклар бик күп, әмма алар барысы да бер милләт тәшкил итмиләр. Г. Гобәйдуллин шул ук вакытта: «бер үк телдә сөйләшеп тә, аерым милләтләр булып, хәтта дошманлыкта яшәү мисаллары да бар», – дип яза (Газиз 1913б: 137). Әмма шул ук вакытта «политикада милләтләргә тел бик зур файда итә». Хәтта чыгышлары белән бер тамырдан булып та, аерым милләт оештырган халыклар бар. Аларга мисал итеп, Г. Гобәйдуллин: «Португалия һәм Испаниянең телләре бер, гыйрклары [ырулары] бер була торып та, икесе ике милләт ясыйлар», – дип яза (Газиз 1913б: 137).

Газиз Гобәйдуллин тел, дин һәм дә дәүләт уртаклыгы гына милләтне билгели алмый, болар милләтне ачыклауда махсус ноктала түгел дип фикерли. Милләт төшенчәсе бер билге белән генә билгеләнә алмый, халык милләт булып ирешсен өчен, берничә факторның булуы мөһим, галимнең фикеренчә, милләтнең асылын билгеләүче фактор – ул гасырлар буе формалашып килгән тарихи якынлык, тарихи бердәмлек. «Милләт – ул кешеләр җыены, милләтнең асыл тарихы ганганәләргә [традицияләргә], хатирәләргә терәлгән була: кешеләр бер-берсенең якынлыгын хис итәләр, һәркайсының бабасының бабалары вә

нәселләре бер дошманга – дошман, бер дустка – дуст, бер җирдә торганга, яисә бергә күчеп йөргәнне халык тарихи җырлары кыяфәтендә күңелдә саклыйлар. Шулай итеп, без милләткә хәзер рухи бер тәгъриф бирәмез: миллият – тарихи ганганәләргә бер булып, берлек хис иткән адәмнәр җыеныдыр» (Газиз 1913 б: 138). Бу очракта «милләт» белән «миллият» төшенчәсе арасындагы мәгънә төсмерләре булуга һәм бу төшенчәләргә салынган эчтәлеккә дә игътибар итү кирәк. Г. Гобәйдуллин, «милләт» төшенчәсенә аңлатма биргәндә, тел факторын күрсәтми, Г. Шәрәф күзаллавы буенча да «милләт» төшенчәсе Г. Гобәйдуллин карашына якын, әмма ул бу очракта тел факторының ролен күрсәтә: «нәселләре бер, тарихлары бәйләнгән, телләре якын халыклар бер милләт тәшкил итәләр», ә «миллият», аның фикеренчә, «шул халыклардагы бер-беренең якынлык тойгысы, бер-берсе илә бәйләнгәнлекләрен хис итүләре миллият дип атала» (Шәрәф 1914: 40–42). XX йөз башында милләт һәм миллият хакындагы фикерләр күп гыйлем ияләре тарафыннан әйтелгән. Алар хакында, аларның фикерләрен анализлаган махсус фәнни мәкалә дә дөнья күрде (Ибрагимов, Киямова 2016: 212–217).

Тарих, тарихи вакыйгалар һәрвакыт хәрәкәттә, милләтләрнең берсе хаким, берсе мәхкүм [ирексез] була. «Беренче очракта хөкүмәт белән миллият җыела, икенчесендә мәгълүб [җиңелгән] төркем генә галиб кешеләрнең ясаган хөкүмәтенә керсә дә, һаман да миллият идеясе бетми» (Газиз 1913а: 397). Газиз Гобәйдуллин фикеренчә, мәхкүм миллият – чын миллияттер, чөнки хаким милләттә, күп вакытта, миллият булудан бигрәк, «дәүләт» булуы хис ителәдер. Тарих милләт алдына төрле сынаулар куя. Г. Гобәйдуллин чорына тарихның тагын бер сынавы – сыйнфый көрәш кушыла. Монда җавабын ул шактый кыска тота: «Миллиятнең хәзерге әһәмияте хакында мин сөйләп тә тормыйм: чөнки гасырымыз – миллият һәм сыйнфый көрәш гасырыдыр. Ләкин соңгы көрәш «милли хискә» һәрвакыт урын биреп бара» (Газиз 1913а: 398). Хәзерге чор күзлегеннән карасак, тарихның милләт алдына үзенең яңа сынауларын куюын күрәбез. Моны узу осталыгы – шулай ук милләтнең халәтен күрсәтүче билге булачак.

Татар халкы һәм аның милләте формалашу тарихы шактый катлаулы, XX йөз башыннан алып, ул тарихи анализ объекты булып кала икән, бу үз чиратында шул катлаулылыкны һәм аның тирәнлеген өйрәнүне таләп итә. XX йөз башы зыялылары фикере буенча да, хәзерге галимнәрнең хезмәтләренә таянып та, шундый нәтиҗәгә килергә мөмкин: татар халкының этноним исеме буларак, үткән тарихының байлыгын исәпкә алган хәлдә, тарих биргән атаманы – «татар» сүзен куллануда киртә булырга тиеш түгел.

ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

Баттал Г. Казан төркиләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.

Газиз 1913а – Газиз Г. Милләтне ничек аңлыйсыз? // Аң. 1913. № 22.

Газиз 1913б – Газиз Г. Милләтне ничек тәгъриф кылырга? // Аң. 1913. № 8.

Газиз 1918а – Газиз Г. Без төрекме, татармы // Корылтай. 1918. № 46. Гыйнвар.

Газиз 1918б – Газиз Г. Төрекме, татармы. Казань: Миллят (Курултай), 1918.

Газиз Г. Милләтне ничек тәгъриф кылырга? // Фәнни Татарстан. 2019. № 2.

Губайдуллин Г.С. К вопросу о происхождении татар // Вестник научного общества татароведения. 1928. № 8.

Ибраһимов Г. «Без кем?» бәхәсе // Г. Ибраһимов. Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007.

Мәрҗани Ш.Б. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

Шәрәф Җан. Ничек аңларга? // Аң. 1914. № 2.

ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Ибрагимов М., Киямова А. Проблема национального в трудах татарских ученых и публицистов начала XX века // Филология и культура. 2016. № 1(43). С. 212–217.

Насретдинова Д.М. Историк Г.С. Губайдуллин (1887–1937): Жизнь и творчество. Автореферат на соискание ученой степени кандидата исторических наук. Казань, 1997.

Автор турында белешмә: Сәлахова Эльмира Кадим кызы, тарих фәннәре кандидаты, Яңа тарих бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин ур., 7А, Казан, Россия Федерациясе); ilsalah@mail.ru

Редакциягә керде 11.08.2022 *Кабул ителде 07.10.2022*

ПОНЯТИЯ «НАРОД», «НАЦИЯ» В ТРУДАХ Г. ГУБАЙДУЛЛИНА

Э.К. Салахова

Институт истории им. Ш. Марджани
Академии наук Республики Татарстан
Казань, Российская Федерация
ilsalah@mail.ru

Конец XIX – начало XX вв. в истории татар – это период осмысления прошлого народа, размышлений об исторических и культурных вопросах, оп-

ределения основных задач его дальнейшего развития. В это время в трудах татарских ученых и публицистов на передний план выходит анализ и рассуждения о национальном, формируются дискуссии о понятиях «народ», «нация», ищется ответ на вопрос «Кто мы?».

Автор статьи обращается к трудам историка Г. Губайдуллина «Милләтне ничек тәгъриф кылырга?» («Как объяснить понятие “милләт”?» (1913) «Төрекме, татармы?» («Тюрки или татары?») (1918), «К вопросу о происхождении татар» (1928) и на их примере исследует рассуждения ученого о названии татарского народа и формировании татарской нации. В работе показывается эволюция идей Г.Губайдуллина о татарской идентичности, проводится сравнительный анализ взглядов историка с рассуждениями ученых – его современников.

Следует особо отметить то, что в последнее время заметно возрос интерес к проблеме татарской идентичности. В связи с этим особую актуальность приобрело изучение данного вопроса в историческом ракурсе – через труды известных ученых начала XX в. Новизна исследования заключается в том, что на основании изучения научных статей первого татарского профессионального историка Г.Губайдуллина показана постановка и осмысление проблемы национальной идентичности татарского народа в начале XX в.

Ключевые слова: нация, национальная идентичность, народ, историк Г. Губайдуллин, национальное, история, культура.

Для цитирования: Салахова Э.К. Г. Гобәйдуллин хезмәтләрендә «халык», «милләт» төшенчәләре // Историческая этнология. 2022. Т. 7, № 3. С. 457–467. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-3.457-467

Сведения об авторе: Салахова Эльмира Кадимовна, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник отдела новой истории, Институт истории им. Ш. Марджани Академии наук Республики Татарстан (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); ilsalah@mail.ru

Поступила 11.08.2022 *Принята к публикации 13.09.2022*

THE CONCEPTS OF “PEOPLE”, “NATION” IN THE WORKS OF G. GUBAYDULLIN

E.K. Salakhova

Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russian Federation
ilsalah@mail.ru

The end of the 19th – early 20th century in the history of the Tatar people is a time of comprehension of their past, reflection on historical and cultural issues, determination of the main tasks of development. During this period, analysis and rea-

soning about the national issues come to the foreground in the works of Tatar scholars and publicists; they discuss the concepts of "people", "nation", raise the question "Who are we?"

In this article, the author refers to the works of historian G. Gubaydullin "Millätne nichek tagrif kylyrga?" (1913), "Törekme, Tatarmy?" (1918), "Revisiting the Question of the Origin of the Tatars" (1928), who, using the example of the listed works, examines his reasoning about the name of the Tatar people, about the formation of the Tatar nation and also shows the evolution of his understanding of the problem of Tatar identity. A comparative analysis of G. Gubaydullin's views on this issue with the arguments of his contemporaries has been conducted.

The fact that recently interest in the problem of Tatar identity has increased remarkably is of particular note. In this respect, the relevance of studying the given problem in the reflections of famous scientists of the early 20th century has increased. The novelty of this study lies in the fact that, the formulation and understanding of the scientific problem of the national identity of the Tatar people at the beginning of the twentieth century is presented based on the works of G. Gubaydullin, the first Tatar professional historian.

Keywords: Nation, national identity, people, historian G. Gubaydullin, national, history, culture.

For citation: Salakhova E.K. G. Gobäydullin khezmätlärendä «khalyk», «millät» töshenchäläre [The concepts of "People", "Nation" in the works of G. Gubaydullin]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2022, vol. 7, no. 3, pp. 457–467. https://doi.org/10.22378/he.2022-7-3.457-467 (In Tatar)

REFERENCES

Ibragimov M., Kiyamova A. Problema natsional'nogo v trudakh tatarskikh uchenykh i publitsistov nachala XX veka [The Problem of the national aspect in the works of Tatar scientists and publicists of the early XX century]. *Filologiya i kultura*, 2016, no. 1(43). (In Russian)

Nasretdinova D.M. *Istorik G.S. Gubaydullin (1887–1937): Zhizn' i tvorchestvo. Aftoref. diss. ... kand. ist. nauk* [Historian G.S. Gubaydullin (1887–1937): Life and Work. Abstract of Cand. Sc. Hist. Diss.]. Kazan, 1997. (In Russian)

About the author: Elmira K. Salakhova, Cand. Sc. (History), Senior Research Fellow of the Department of New History, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); ilsalah@mail.ru

Received August 11, 2022 Accepted for publication September 13, 2022